СОВЕТ
НОВОКИШИТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Дружба, д. 100а, с. Новый Кишит,
Арский муниципальный район, 422034

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КИШЕТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Дуслык урамы, 100а йорт, Яңа Кишет авылы,
Арча муниципаль районы, 422034

Тел. (84366)55-4-42, факс (84366)55-4-42. E-mail: Nvk.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районы**
**Яңа Кишет авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**05 май 2021ел** **№ 23**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Советының 2015 елның 03 ноябрендәге 8 нче номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында (29.11.2018 №16, 16.10.2019 №37 карарлар редакциясендә)**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Яңа Кишет авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына яраклаштырып, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Советының 2015 елның 03 ноябрендәге 8 нче номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына (29.11.2018 №16, 16.10.2019 №37 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пунктның 1.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 3.1 пунктча өстәргә:

«3.1. Физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән түбәндәгеләрне азат итәргә:

3.1.1. 18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарны;

3.1.2. Әлеге пунктның 3.1.1. пунктчасында күрсәтелгән гражданнарның балаларын.

Салым ташламасы түбәндәге төр салым салу объектларына карата бирелә:
- фатир, фатирның бер өлеше яисә бүлмә;
- торак йорт яисә торак йортның бер өлеше;
- гараж яки мәйданы 30 кв метрдан да артык булмаган машина урыны.

Салым ташламасы, салым ташламаларын куллану өчен нигезләр санына бәйсез рәвештә, салым түләүченең теләге белән гаиләгә туры килә торган һәр салым салу объектына карата бирелә.

Салым ташламасы Яңа Кишет авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче салым түләүчеләргә салым түләүче тарафыннан салым түләүче милкендәге һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган салым салу объектына карата булган салым суммасы күләмендә бирелә.

Салым ташламаларына хокукы булган физик затлар салым органына салым ташламалары бирү турында гаризаны үз сайлавы буенча бирә, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган документларны тапшырырга хокуклы.

Салым ташламасына хокукны раслаучы документлар түбәндәгеләр:
- әлеге салым буенча салым түләүче дип танылган физик затның шәхесен таныклаучы документ;
- аның исеменә бирелгән күпбалалы гаилә таныклыгы.